**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарманавылжирлеге**
**423350 Сарманавылы, М.Жэлилур., 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.М.Джалиля, 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09 август 2023 ел № 4

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Сарман авыл җирлегенең 2021 елның 27 декабрендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар чыгарды:

1. Әлеге准 карарга кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2022 елның 25 ноябрендәге 21 номерлы карары белән расланган «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проект буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» проектын әзерләү комиссиясе - үткәрү датасы һәм вакыты - 2023 елның 24 августы 14.00 сәгатьтә;

- үткәрелү урыны - Сарман авылы, Ленин урамы, 28 киноучреждение бинасындагы конференция залында;

- язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Татарстан Республикасы Сарман авылы, Куйбышев урамы, 31а йорт адресы буенча Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитетына кертелергә мөмкин,(эш

көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2022 елның 25 ноябрендәге 21 номерлы карары белән расланган «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проектын әзерләү комиссиясе:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2022 елның 25 нояббрендәге 21 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

4. Башлыкның әлеге карарын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http/ sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

«Сарман авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
Башлыгы Ф.М.Хөснуллин

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башлыгының 2023 елның 09 нчы августындагы № 4 карарына 1 нче кушымта

**Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә кертү турында**

1. 2 бүлекнең 4.1 пунктын төшереп калдырырга;
2. 3.6.1 пунктының «й» пунктчасында «тимер юллар,» сүзләрен төшереп калдырырга;
3. 3.7.2 пунктындагы «д» пунктчасында «һәм тимер юл» сүзләрен төшереп калдырырга;
4. 3 бүлекнең 3.11.8, 3.11.9, 3.11.10 пунктларында «(тимер юл)» сүзләрен төшереп калдырырга;
5. 4 бүлекнең 4.2.7 пунктын төшереп калдырырга.